# КАРАР

## Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге составына керүче Иске Маврин торак пункты гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**10.11.2020** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2020 елның 10 ноябрендә «Көндезге бүлектә укучы студентлар, I группа инвалидлар, һәм ялгыз өлкәннәрдән кала, яшәү урыны буенча Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлегенең Иске Маврин авылында теркәлгән, балигъ булган һәр гражданга 2021 елда үзара салымны 500 (биш йөз) сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны

- Төзүчеләр урамы буйлап юлга вак таш түшәү;
- өеп ясалган күпергә вак таш түшәү өчен тотарга сез ризамы», дигән мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре нигезендә беркетмә төзелде:

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:
сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 166 граждан кертелде, гражданнар җыенында тавыш бирүдә 89 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен 66 җыенда катнашучы тавыш бирде;
«Юк» позициясе өчен 23 җыенда катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлегенең Иске Маврин торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. «Көндезге бүлектә укучы студентлар, I группа инвалидлар һәм ялгыз өлкәннәрдән кала, яшәү урыны буенча Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлегенең Иске Маврин авылында теркәлгән, балигъ булган һәр гражданга 2021 елда үзара салымны 500 (биш йөз) сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны Төзүчеләр урамы буйлап юлга вак таш түшәү, өеп ясалган күпергә вак таш түшәү өчен тоту мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Иске Маврин**
**авыл җирлеге башлыгы** **Р.Г.Нургалиев**